**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «23» апреленнән № 97

**«Хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында Нигезләмәне раслау хакында»**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 353.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы учреждениеләрдә хезмәт законнары үтәлешенә ведомство контролен тәэмин итү максатларында, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләрендә хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турындагы кушымта нигезендә бирелгән Нигезләмәне (алга таба - Нигезләмә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдиренә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерергә һәм расланган Нигезләмәне ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренә эштә куллану өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет" мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге

рәсми сайтында «http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**

Кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «23» апрелендәге
№ 97 карарына

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләрендә хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контролендә тоту турында
Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан Татарстан Республикасының ведомство карамагындагы муниципаль учреждениеләрендә (алга таба – ведомство карамагындагы учреждениеләр) хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәүнең ведомство контроле (алга таба – ведомство контроле) буенча тикшерүләр үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Тикшерү уздырганда Башкарма комитетның ведомство контроле буенча чаралар үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары (алга таба – вәкаләтле вазыйфаи затлар) Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, федераль һәм республика законнарына, хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган норматив хокукый актларга, әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Ведомство контролен үткәрү нигезе һәм оештыру тәртибе

2.1. Ведомство контролен тормышка ашырганда планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрелә.

2.2. Планлы тикшерүләр Башкарма комитет җитәкчесе раслаган еллык план нигезендә үткәрелә.

Планда ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең исеме, аларның урнашу урыны, тикшерү үткәрү вакыты, җаваплы башкаручы күрсәтелә.

Киләсе календарь елга тикшерүләр үткәрү Планы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Башкарма комитетның рәсми сайтында агымдагы елның 31 декабренә кадәр урнаштырыла.

План буенча тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

2.3. Ведомство карамагындагы учреждениеләргә карата хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый

актларның үтәлешенә дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында тикшерү үткәрелгән булса, планлы тикшерү әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вакытка күчерелергә тиеш.

2.4. Планлы тикшерүне уздырганда учреждениеләр тарафыннан РФ ХК нормаларын, хезмәт өлкәсендә федераль һәм республика законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны, шул исәптән тармак норматив хокукый актларын һәм килешүләрне үтәү билгеләнә.

2.5. Планлы тикшерүне уздырганда ведомство тикшерүенең төп юнәлеше булып түбәндәге мәсьәләләрне карау тора:

хезмәт килешүе;

эш вакыты;

ял вакыты;

хезмәткә түләү һәм нормалаштыру;

хезмәткәрләренә бирелә торган гарантияләрне һәм компенсацияләрне үтәү;

хезмәт тәртибе һәм хезмәт дисциплинасы;

хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлеге, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү;

хезмәтне саклау;

хезмәт килешүе якларының матди җаваплылыгы;

аерым категория хезмәткәрләрнең хезмәтен җайга салу үзенчәлекләре;

хезмәткәрләргә аттестация үткәрү.

Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә контроль буенча чаралар үткәргәндә соратып алына торган хокукый һәм локаль норматив актлар, документлар исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән.

2.6. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып, түбәндәгеләр тора:

Башкарма комитетка хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозу турында шикаять яки башка мөрәҗәгать керү;

әгәр дә ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесе тарафыннан срокны озайту турында гариза тапшырылмаган булса, ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесе тарафыннан элегрәк ачыкланган бозуларны бетерү турында хисап тапшырылмаган очракта.

Планнан тыш тикшерү үткәрү турында ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесе Башкарма комитет тарафыннан, аны үткәрү башланганчы, бер эш көненнән дә ким булмаган срокта, теләсә нинди үтемле ысул белән хәбәр ителә.

2.7. Планлы яисә планнан тыш тикшерү үткәрү вакыты егерме эш көненнән дә артмаска тиеш.

Катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр үткәрү зарурлыгына бәйле аерым очракларда, тикшерү үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затларның мотивлаштырылган тәкъдимнәре нигезендә, тикшерү үткәрү вакыты егерме эш көненнән дә артмаган срокка озайтылырга мөмкин.

2.8. Әлеге Нигезләмәдә каралган тикшерү үткәрү нигезләре булганда, тикшерү үткәрү турында боерык чыгарыла.

Тикшерү үткәрү турында күрсәтмәдә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

тикшерү үткәрү турында боерык номеры һәм датасы;

тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы;

тикшерү үткәрелә торган ведомство карамагындагы учреждениенең исеме;

тикшерүнең максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү вакыты;

тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре.

Ведомство карамагындагы учреждениене төрле юнәлешләр буенча тикшерү үткәргән очракта, боерык нигезендә контроль буенча чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы төркем җитәкчесе билгеләнә.

2.9. Ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесенә, тикшерүне үткәрү турында боерыкның расланган күчермәсен җибәрү юлы белән, тапшыру турында уведомление белән почта аша яки башка мөмкин булган ысул белән, планлаштырылган тикшерү турында кимендә 3 эш көне алдан хәбәр ителә.

Тикшерү турындагы хәбәрне җиткерүнең башка үтемле ысулы булып, тикшерүче затның вәкаләтле вәкиленнән күрсәтмәнең күчермәсен алу турындагы расписканы алу, яки күрсәтмәнең икенче нөсхәсендә алу датасы, имза, Ф.И.О. һәм вазыйфасын үз эченә алган билге кую тора. Тикшерелүче затның урнашу урыны ерак булган очракта, тикшерү турында күрсәтмәнең күчермәсен факсимиль элемтә каналы аша, соңыннан алучының имзасы, Ф.И.О һәм вазыйфасын, алу датасын күрсәтеп, факсимиль элемтә каналы аша кире кайту юлы белән җибәрелергә мөмкин.

2.10. Тикшерүләр тикшерү үткәрү турында боерыкта күрсәтелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

2.11. Вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү башланыр алдыннан җитәкчегә яки ведомство карамагындагы учреждениенең башка вазыйфаи затына хезмәт таныклыгын яки шәхесне раслаучы башка документ күрсәтергә тиеш.

2.12. Тикшерү үткәргәндә Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи затлары ведомство карамагындагы учреждениенең объектларында (территорияләрендә һәм бүлмәләрендә) йөрергә, ведомство карамагындагы учреждениенең вазыйфаи затларыннан тикшерү уздыру өчен кирәкле документлар һәм аңлатмалар алырга хокуклы.

2.13. Ведомство карамагындагы учреждениедә тикшерү уздырганда вәкаләтле вазыйфаи затлар хокуклы түгел:

ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесе яки аның вазыйфаларын башкаручы зат булмаганда, тикшерү үткәрергә;

әгәр мондый таләпләр үткәрелә торган тикшерү предметына кагылмаса, законнардагы һәм башка норматив хокукый актларның мәҗбүри таләпләренең үтәлешен тикшерү;

үткәрелә торган тикшерү предметына керми торган документлар, мәгълүмат бирүне таләп итү;

тикшерү нәтиҗәсендә алынган, дәүләт, хезмәт яки закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны таратырга;

әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тикшерүне үткәрү срокларыннан артып китәргә.

2.14. Җитәкче, аның урынбасары яисә ведомство карамагындагы учреждениенең башка вазыйфаи заты тарафыннан тикшерү үткәрүгә комачаулаган очракта, Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи затлары тикшерү үткәрүдән баш тарту турында акт төзергә, яисә ведомство контролен үткәрү өчен кирәкле документлар һәм локаль норматив актлар тапшырмау турында акт төзергә тиеш.

2.15. Ведомство контролен гамәлгә ашырганда күчмә тикшерүләр (планлы һәм планнан тыш) – ведомство карамагындагы учреждениенең урнашу урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шулай ук документар тикшерүләр (планлы һәм планнан тыш ) - Башкарма комитетның урнашу урыны буенча үткәрелә.

## III. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

3.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә тикшерү акты төзелә, анда түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

тикшерү үткәрү турында боерык датасы һәм номеры;

тикшерү үткәргән затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы;

ведомтсво карамагындагы учреждениенең исеме;

җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы;

тикшерү үткәрү датасы, вакыты, озынлыгы һәм урыны;

контроль буенча үткәрелгән чаралар исемлеге;

тикшерү нәтиҗәләре, шул исәптән хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозу ачыкланган очракта, хокук бозу характеры турында һәм әлеге бозуларга юл куйган учреждениенең вазыйфаи затлары турында белешмәләр;

ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесенә тикшерү акты тапшыру турында белешмәләр;

тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның имзалары.

Тикшерүне берничә вәкаләтле вазыйфаи зат төрле юнәлешләрдә үткәргән очракта, актны контроль буенча чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы төркем җитәкчесе төзи.

Тикшерү актына тикшерү нәтиҗәсендә алынган документлар яки аларның күчермәләре, ведомство буйсынуындагы учреждениенең вазыйфаи затларының язма аңлатмалары теркәлә.

3.2. Тикшерү акты ике нөсхәдә төзелә, актның икенче нөсхәсе ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесенә яки аның вәкаләтле затына расписка белән тапшырыла.

Ведомство буйсынуындагы учреждение җитәкчесе яисә аның вәкаләтле заты булмаган очракта, шулай ук тикшерү акты алган өчен расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт заказлы почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе белән җибәрелә, ул Башкарма комитетта саклана торган тикшерү актының беренче нөсхәсенә теркәлә.

3.3. Башкарма комитет тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

## IV. Тикшерү барышында ачыкланган бозуларны бетерү

4.1. Ведомство контроле буенча чаралар үткәрү нәтиҗәләре буенча ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесе ачыкланган җитешсезлекләрне 15 календарь көн эчендә бетерергә бурычлы.

4.2. Актта күрсәтелгән срок чыкканнан соң, ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесе бозуларны бетерү турында Башкарма комитетка хисап тапшырырга тиеш. Хисапка җитешсезлекләрне бетерүне раслаучы документлар һәм материалларның күчермәләре теркәлә.

4.3. Билгеләнгән вакыт үткәннән соң ачыкланган бозулар бетерелмәгән яисә ведомство карамагындагы учреждение җитәкчесе аларны бетерүдән баш тарткан очракта, ведомство контроле буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә ачыкланган хезмәт законнарын бозу турында мәгълүмат Татарстан Республикасының Дәүләт Хезмәт инспекциясенә җибәрелә.

## V. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең һәм аларның вазыйфаи затларының җаваплылыгы

5.1. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр, аларның вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны бозган өчен җаваплы.

## VI. Контроль буенча чараларны исәпкә алу

6.1. Башкарма комитет вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә карата үткәрелгән тикшерүләрнең исәбен алып бара.

6.2. Контроль буенча чараларны исәпкә алу, Башкарма комитетның ведомство контролен гамәлгә ашыручы бүлекләре тарафыннан, әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында бирелгән тикшерүләрне исәпкә алу журналын алып бару юлы белән башкарыла. Әлеге журнал тегелгән, нумерланган, имза белән беркетелгән һәм Башкарма комитет мөһере белән расланган булырга тиеш.

6.3. Ведомство карамагындагы учреждениеләр хезмәт законнары үтәлешен һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәү буенча үткәрелгән тикшерүләрнең исәбен мөстәкыйль рәвештә үзләре алып баралар.

## VII. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары гамәлләренә шикаять белдерү

7.1. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары гамәлләренә шикаять бирү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Хезмәт законнарын үтәү буенча
ведомство контролен үткәрү турында
Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы

Ведомство
карамагындагы учреждениеләрдә
контроль буенча чаралар үткәргәндә соратып алына торган
хокукый һәм локаль норматив актлар, документлар Исемлеге

Күмәк килешү;

эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре;

ведомство буйсынуындагы учреждениенең хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган, хезмәткәрләрнең хезмәт функциясенә кагылышлы мәҗбүри таләпләрне, шул исәптән хезмәт өчен түләү, премияләү, компенсация һәм стимуллаштыручы түләүләр турында нигезләмәләрне билгели торган локаль норматив актлары;

штат расписаниесе;

яллар графигы;

хезмәт шартнамәләре, хезмәт килешүләрен һәм аларга кертелгән үзгәрешләрне теркәү журналы;

хезмәт кенәгәләре, хезмәт кенәгәләре хәрәкәтен исәпкә алу китабы, хезмәт кенәгәсе һәм аңа вкладыш бланкларын исәпкә алу буенча керем-чыгым китабы;

җитәкчеләр һәм белгечләрнең шәхси эшләре, хезмәткәрләрнең шәхси карточкалары (Т-2 формасы), хезмәткәрләрнең хезмәт вазыйфаларын билгели торган документлар;

шәхси состав буенча приказлар (кабул итү, эштән азат итү, башка эшкә күчү һ. б.));

отпусклар, командировкалар турында приказлар;

төп эшчәнлек буенча боерыклар;

боерыкларны теркәү журналлары;

эш вакытын исәпкә алу табеле;

түләү документлары;

хезмәт хакы бирү буенча ведомостьләр;

исәп-хисап кәгазьләре;

өч яшькә кадәр балалары булган хатын-кызлар , балигъ булмаган хезмәткәрләр, инвалид хезмәткәрләр һәм йөкле хатын-кызлар исемлеге;

медицина белешмәләре;

матди җаваплылык турында килешүләр;

аттестация турында нигезләмә, аттестация комиссиясен төзү турында боерык, бәяләмәләр, аттестацион битләр;

хезмәтне саклау буенча җаваплы итеп билгеләү турында боерык;

хезмәтне саклау буенча эшне оештыру турында нигезләмә;

кереш инструктаж үткәрү буенча журнал;

эш урынында беренче тапкыр, кабат, планнан тыш, максатчан инструктажларны теркәү журналы;

хезмәтне саклау буенча кереш инструктаж программасы;

эш урынында хезмәтне саклау буенча беренчел инструктаж программасы;

хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү картасы;

хезмәтне саклау таләпләрен белүне тикшерү буенча даими эшләүче комиссия төзү турында боерык;

хезмәтне саклау таләпләрен өйрәнү һәм белемнәрне тикшерү турында боерык;

хезмәтне саклау таләпләрен белүне тикшерү турында таныклыклар;

белемнәрне тикшерү буенча комиссия беркетмәсе;

хезмәтне саклау буенча инструкцияләрне раслау һәм гамәлгә кертү турында боерык;

вазыйфалар/һөнәрләр/эш төрләре буенча хезмәткәрләр өчен хезмәтне саклау буенча инструкцияләр;

хезмәтне саклау буенча инструкцияләр бирүне исәпкә алу журналы;

эш урынында стажировка узучы хезмәткәрләр һәм һөнәрләр исемлеге;

«Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә тапшырылган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында хисап (мәгълүмат) ;

тулы һәм һәрьяклы тикшерү уздыру өчен кирәкле башка локаль норматив актлар һәм документлар.

Хезмәт законнарын үтәү буенча
ведомство контролен үткәрү турында
Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты

________________________ «__» _____________ 20__ ел
(актны төзү урыны) (актны төзү датасы)

__________________________
(акт төзү вакыты)

# ТИКШЕРҮ АКТЫ
№ __________

Тикшерү __________________________________________________адрес буенча
(тикшерү үткәрү урыны)

______________________________________________________________________
(реквизитлары (номеры, датасы) күрсәтелгән документ төре )

____________________________________________________________нигезендә,
(планлы/планнан тыш)

______________________________________________________________________
_______________________________________________________ карата үткәрелде.
(ведомство буйсынуындагы учреждениенең исеме, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы)

Тикшерү үткәрү датасы һәм вакыты:

«__» ___ 20__ ел. ____сәгать____минуттан____сәгать. ____ минутка кадәр.
Озынлыгы ___
«__» ___ 20__ ел. ___ сәгать____минуттан____сәгать. ____ минутка кадәр.
Озынлыгы ___

Тикшерүнең гомуми озынлыгы :
_____________________________________________________
(эш көннәре/сәгать)

Акт Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан төзелде.
Тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәнең күчермәсе белән таныштым(тык):
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(фамилия, инициаллар, имза, дата, вакыт)

Тикшерү үткәргән зат(лар):

______________________________________________________________________________

(тикшерү үткәргән вазифаи затның(вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Тикшерү барышында катнаштылар: ____________________________________
( тикшерү барышында катнашкан җитәкченең

______________________________________________________________________________

яки ведомство карамагындагы учреждениенең вазыйфаи затының

______________________________________________________________________________

фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы)

Тикшерү нәтиҗәләре турында белешмәләр:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Актка теркәлә торган документлар:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Тикшерү үткәргән затларның имзалары:

_____________________________________________

_____________________________________________

_____________________________________________

Ачыкланган бозуларны бетерү срогы-15 календарь көн.

Тикшерү акты белән таныштым, барлык кушымталар белән актның күчермәсен алдым:

______________________________________________________________________________

(ведомство буйсынуындагы учреждениенең җитәкчесе яисә аның вәкаләтле вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

«__» _______________ 20__ ел

________________
(имза)

Тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында билге:

_____________________________
(тикшерү үткәргән вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) имзасы)

Хезмәт законнарын үтәү буенча
ведомство контролен үткәрү турында
Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство карамагындагы муниципаль учреждениеләренә карата үткәргән тикшерүләр
ЖУРНАЛы

<table>
<tr><th rowspan="3">№ т/б</th><th rowspan="3">Ведомство буйсынуындагы учреждениенең исеме</th><th rowspan="3">Тикшерү төре</th><th colspan="4">Контроль буенча чаралар үткәрү вакыты</th><th rowspan="3">Тикшерү үткәрү өчен хокукый нигезләр (План, боерык, мөрәҗәгать һ. б.))</th><th rowspan="3">Тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актны төзү датасы һәм № <**></th><th rowspan="3">Вәкаләтле вазыйфаи зат (лар)</th><th rowspan="3">Вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) имзалары</th></tr>
<tr><th colspan="2">план нигезендә <*></th><th colspan="2">фактта,</th></tr>
<tr><th>башлану датасы</th><th>тәмамлану датасы</th><th>башлану датасы</th><th>тәмамлану датасы</th></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

<*> Планлы тикшерүләр вакытында тутырыла.
<**> Актлар әлеге журналга кушымта булып тора һәм аның белән бергә саклана